**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об отдельных вопросах организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 декабря 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 26 декабря 2015 года № 107-ЗРТ «Об отдельных вопросах организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 12 (I часть); 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2018, № 29 (часть I); 2022, № 57 (часть I); 2023, № 35 (часть I) следующие изменения:

1) в части 2 статьи 3:

а) в пункте 4 после слов «в таком конкурсе» дополнить словами «, утверждает конкурсную документацию», слово «перевозчикам» исключить;

б) дополнить пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$) устанавливает порядок предоставления дубликата свидетельства об осуществлении перевозок по межмуниципальному маршруту регулярных перевозок и дубликата карты маршрута регулярных перевозок, предоставляет дубликат свидетельства об осуществлении перевозок по межмуниципальному маршруту регулярных перевозок и дубликат карты маршрута регулярных перевозок;»;

в) в пункте 7 слова «межрегиональным и» исключить;

г) пункт 8 изложить в следующей редакции:

«8) устанавливает в соответствии с пунктом 4 статьи $3^5$ и пунктом 5 части 1 статьи 6 Федерального закона требования к экологическим характеристикам транспортных средств, используемых для осуществления регулярных перевозок по

международному и межрегиональному маршрутам регулярных перевозок, проходящим в границах Республики Татарстан;»;

2) в статье 4:

а) в пункте 4 после слов «в таком конкурсе» дополнить словами «, утверждают конкурсную документацию», слово «перевозчикам» исключить;

б) дополнить пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$) устанавливают порядок предоставления дубликата свидетельства об осуществлении перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок и дубликата карты маршрута регулярных перевозок, предоставляют дубликат свидетельства об осуществлении перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок и дубликат карты маршрута регулярных перевозок;»;

3) в статье 5:

а) в части 2 слова «соответствующего городского округа» заменить словами «городского округа»;

б) в части $4^1$ слова «изменение муниципального» заменить словами «изменение межмуниципального», слова «либо межмуниципального» заменить словами «либо муниципального»;

в) в части 7 цифры «1 – 11» заменить цифрами «1 – 10», цифры «3 – 11» заменить цифрами «3 – 10, 12», слова «исключения сведений о данных маршрутах из реестров» заменить словами «внесения сведений об отмене данных маршрутов в реестры»;

4) часть 3 статьи $5^1$ дополнить предложением следующего содержания: «Формат размещения указанных сведений должен предусматривать возможность их отбора и сортировки с использованием программ для электронных вычислительных машин и баз данных, предназначенных для создания, просмотра и редактирования текстовых файлов и электронных таблиц.»;

5) в статье 7:

а) часть 2 после слов «по маршруту регулярных перевозок» дополнить словами «(далее – открытый конкурс)»;

б) в части 3:

в пункте 1 слова «частью 10 статьи 24 либо пунктом 1, 2 или 7» заменить словами «пунктами 1, 2, 7, 9 и 11»;

дополнить пунктами 3 и 4 следующего содержания:

«3) в случае невыполнения юридическим лицом, индивидуальным предпринимателем или уполномоченным участником договора простого товарищества обязанности осуществлять регулярные перевозки в соответствии с частью 3 статьи 29 Федерального закона до начала осуществления регулярных перевозок в соответствии с новым свидетельством об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок, выданным по результатам проведения открытого конкурса;

4) после наступления обстоятельств, предусмотренных частью 7 статьи 29 Федерального закона.»;

в) в части 4 слова «в день» заменить словами «в течение трех дней со дня»;

г) часть 6 изложить в следующей редакции:

«6. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченный орган местного самоуправления, выдавшие свидетельство об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок, обращаются в суд с заявлением о прекращении действия данного свидетельства при наступлении хотя бы одного из обстоятельств, предусмотренных частью 5 статьи 29 Федерального закона.»;

6) в статье $7^1$:

а) в абзаце первом слово «Юридические» заменить словами «1. Юридические»;

б) пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3) информирование не позднее чем за 15 дней до дня начала применения измененных тарифов уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан и владельцев автовокзалов или автостанций в случае нахождения остановочного пункта на их территории об изменении тарифов на регулярные перевозки по межмуниципальным маршрутам;»;

в) дополнить пунктом 5 следующего содержания:

«5) соблюдение установленного нормативным правовым актом уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан ограничения по экологическим характеристикам транспортного средства.»;

г) дополнить частью 2 следующего содержания:

«2. Сведения о нарушениях требований, предусмотренных частью 1 настоящей статьи, размещаются на официальном сайте уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».»;

7) в статье $7^2$:

а) в наименовании слова «межрегиональному и международному» исключить;

б) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Остановочные пункты, расположенные вне территории автовокзала или автостанции, должны быть оборудованы в соответствии с требованиями, установленными Правилами перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом. Размещение информации на указателях остановочных пунктов, расположенных вне территории автовокзала или автостанции, организуется уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан.»;

8) часть 3 статьи 11 признать утратившей силу.

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением подпунктов «а» – «в» пункта 1, пунктов 2 – 4, подпунктов «б» – «г» пункта 5, подпунктов «а» – «в» пункта 6 и пункта 7 статьи 1 настоящего Закона.

2. Подпункты «а» – «в» пункта 1, пункты 2 – 4, подпункты «б» – «г» пункта 5, подпункты «а» – «в» пункта 6 и пункт 7 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 сентября 2024 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
23 декабря 2023 года
№ 133-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 18 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) 4 пунктта «билгели» сүзеннән соң «, конкурс документларын раслый» сүзләрен өстәргә, «йөртүчеләргә» сүзен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасының дубликатын бирү тәртибен билгели, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хакында таныклыкның дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасының дубликатын бирә;»;

в) 7 пунктта «регионара һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Федераль законның $3^5$ статьясындагы 4 пункты һәм 6 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара һәм регионара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына таләпләрне билгели;»;

2) 4 статьяда:

а) 4 пунктта «билгелиләр» сүзеннән соң «, конкурс документларын раслыйлар» сүзләрен өстәргә, «йөртүчеләргә» сүзен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4[1] пункт өстәргә:

«4[1]) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасының дубликатын бирү тәртибен билгелиләр, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хакында таныклыкның дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасының дубликатын бирәләр;»;

3) 5 статьяда:

а) 2 өлештә «тиешле шәһәр округының» сүзләрен «шәһәр округының» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4[1] өлештә «муниципаль маршрутын» сүзләрен «муниципальара маршрутын» сүзләренә алмаштырырга, «муниципальара маршрутын» сүзләрен «муниципаль маршрутын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлештә «1 – 11» саннарын «1 – 10» саннарына алмаштырырга, «3 – 11» саннарын «3 – 10, 12» саннарына алмаштырырга, «реестрларыннан шушы маршрутлар турында белешмәләр төшереп калдырылган» сүзләрен «реестрларына шушы маршрутларны туктату хакында белешмәләр кертелгән» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5[1] статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру форматы, электрон исәпләү машиналары өчен программаларны һәм текстлы файлларны, электрон таблицаларны булдыру, карау һәм редакцияләү өчен билгеләнгән белешмәләр базаларыннан файдаланып, бу белешмәләрне сайлап алу һәм сортларга аеру мөмкинлеген күздә тотарга тиеш.»;

5) 7 статьяда:

а) 2 өлештә «ачык конкурс» сүзләреннән соң «(алга таба – ачык конкурс)» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә:

1 пунктта «24 статьясындагы 10 өлешендә йә 29 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2 яисә 7 пунктларында» сүзләрен «29 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2, 7, 9 һәм 11 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3 һәм 4 пунктлар өстәргә:

«3) юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы, ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында яңа таныклык нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлаганчы, Федераль законның 29 статьясындагы 3 өлеше нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу бурычын үтәмәгән очракта;

4) Федераль законның 29 статьясындагы 7 өлешендә каралган хәлләр барлыкка килгәннән соң.»;

в) 4 өлештә «көндә» сүзен «көннән алып өч көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турындагы таныклык биргән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы, Федераль законның 29 статьясындагы 5 өлешендә каралган шартларның кимендә берсе генә барлыкка килсә дә, бу таныклыкның гамәлдә булуын туктату хакында гариза белән судка мөрәҗәгать итәләр.»;

6) $7^1$ статьяда:

а) беренче абзацта «Юридик» сүзен «1. Юридик» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, автовокзаллар һәм автостанцияләр хуҗаларына, тукталыш пункты аларның территориясендә булган очракта, үзгәргән тарифларны куллану башланган көнгә кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча муниципальара маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифларын үзгәртү турында хәбәр итүне;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый акты белән билгеләнгән транспорт чарасының экологик характеристикалары буенча чикләүне үтәүне.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган таләпләрне бозу турында белешмәләр вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

7) $7^2$ статьяда:

а) исемдә «йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм халыкара» сүзләрен «йөртү һәм багаж ташу» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Автовокзал яисә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында

пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләр нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш. Автовокзал яисә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары күрсәткечләрендә мәгълүмат урнаштыру вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан оештырыла.»;

8) 11 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» – «в» пунктчаларыннан, 2 – 4 пунктларыннан, 5 пунктының «б» – «г» пунктчаларыннан, 6 пунктының «а» – «в» пунктчаларыннан һәм 7 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» – «в» пунктчалары, 2 – 4 пунктлары, 5 пунктының «б» – «г» пунктчалары, 6 пунктының «а» – «в» пунктчалары һәм 7 пункты 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 23 декабрь
№ 133-ТРЗ